**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5655**
**01.11.2019**

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 25 сентябрендәге 5515 нче карары белән расланган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турында нигезнамәгә, түбәндәге эчтәлектәге 4 бүлек белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«4 бүлек. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәргәндә фикер каршылыкларын хәл итү

36. Тискәре бәяләмә нәтиҗәсендә, акт яки норматив хокукый акт проекты буенча фикер каршылыклары булганда, профильле бүлек тискәре бәяләмәне алган көннән башлап 15 эш көненнән дә соңга калмыйча киңәшмә үткәрә.

37. Фикер каршылыкларын хәл итү Башкарма комитет Җитәкчесе янындагы киңәшмәдә кызыксынучы затлар катнашында гамәлгә ашырыла, шунда ахыргы карар кабул ителә.

38. Киңәшмәдә кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә профильле бүлекчә тарафыннан киңәшмә үткәрелгән датадан башлап 3 эш көненнән дә соңга калмыйча төзелә. Беркетмә киңәшмәдә рәислек итүче тарафыннан имзалана.

39. Фикер каршылыкларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар профильле һәм вәкаләтле бүлекчәләр өчен мәҗбүри булып тора һәм беркетмәдә күрсәтелгән срокта үтәлергә тиеш».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин